ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының 1 һәм 2 пунктлары белән, шул карарга 2 нче кушымта белән тулысынча, шулай ук аның аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.М. Равилов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2017 елның 2 феврале

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Р.М. Равилов шикаятен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Р.М. Равилов «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган 2 нче кушымта белән социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем

килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәр торак урыннарны карап тотуга түләү күләме хезмәт төрләре буенча билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Р.М. Равилов — күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе. Ул күрсәткәнчә, дәгъвалана торган 2 нче кушымта белән торак урыннарны карап тотуга түләү яллаучылар һәм милекчеләр өчен Казан шәһәренең бөтен торак фонды өчен бер күләмдә билгеләнә, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, торак урынны карап тотуга түләү күләме һәр күпфатирлы йорт өчен аерым билгеләнергә тиеш. Үз позициясен нигезләп, ул, аерым алганда, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Мөрәҗәгатьне карау турында» 2016 елның 17 мартындагы 7513-ОЛ/04 номерлы хатын күрсәтә, аның эчтәлегеннән аңлашылганча, җирле үзидарә органнары тарафыннан урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлауга түләү күләме билгеләнгәндә, шул исәптән конкрет күпфатирлы йортның конструктив элементларын һәм үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк.

Мөрәҗәгать итүчедән шикаятькә өстәмә килде, анда ул «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының 1 һәм 2 пунктлары нигезләмәләренең конституциячеллегенә дәгъва белдерә, алар белән торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләменең гамәлдә булу чорлары расланган, атап әйткәндә, тиешенчә 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 30 июненә кадәр һәм 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәр.

Гражданин Р.М. Равилов билгеләгәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме бер елдан да ким булмаган вакытка билгеләнә. Ләкин югарыда күрсәтелгән пунктлар белән торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме елга ике тапкыр расланган, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче дәгъвалана торган 2 нче кушымтаның аерым нигезләмәләренең конституциячеллегенә дәгъва белдерә, атап әйткәндә, 3 пунктның гомуми файдалану урыннарын җыештыру хезмәте өчен тариф билгели торган икенче абзацы, шулай ук 4 пунктның торак бинага; күмәк (гомумйорт) җылылык энергиясен исәпләү приборлары, җылылык сарыф итүне автоматик рәвештә көйләү системалары белән җиһазланмаган йорт эчендәге үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системаларына; күмәк (гомумйорт) җылылык энергиясен исәпләү приборлары белән җиһазланган, җылылык сарыф итүне автоматик рәвештә көйләү системалары белән җиһазланмаган йорт эчендәге үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системаларына; күмәк (гомумйорт) җылылык энергиясен исәпләү приборлары һәм җылылык сарыф итүне автоматик рәвештә көйләү системалары белән җиһазланган йорт эчендәге үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системаларына; газ ярдәмендә эшләүче җиһазлар гомуми файдалану урыннарында урнаштырылган йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау хезмәтләре өчен тарифлар билгели торган икенче, унынчы, унберенче, уникенче һәм унбишенче абзацлары.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, карала торган 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы икенче абзацы, 4 пунктындагы икенче, унынчы, унберенче, уникенче һәм унбишенче абзацлары белән билгеләнгән, 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булган тарифлар үткән чор (2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 30 июненә кадәр) белән чагыштырганда күтәрелгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Р.М. Равилов Татарстан

Республикасы Конституция судыннан «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының 1 һәм 2 пунктларын, әлеге карарга 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы икенче, унынчы, унберенче, уникенче һәм унбишенче абзацларын, шулай ук шул карарга 2 нче кушымтаны тулысынча Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы нигезендә закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт судта яисә башка органда карау төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга шикаять бирү мөмкин була.

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 3 өлеше һәм 158 статьясындагы 4 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре мәгънәсеннән чыгып, әгәр торак урыннар милекчеләре күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм (яки) үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә. Димәк, дәгъва белдерелә торган нормалар белән билгеләнгән хокукый җайга салу торак законнарының китерелгән нигезләмәләре кысаларында кабул ителгән, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләренә генә кагыла.

Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән

материаллардан аңлашылганча, гражданин Р.М. Равилов яшәгән күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләре гомуми җыелышта күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлаганнар һәм торак урынны карап тоту (гомумйорт милеген карап тоту һәм ремонтлау) өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул иткәннәр. Димәк, дәгъвалана торган норматив нигезләмәләр мөрәҗәгать итүченең конкрет эшендә кулланылмаганнар һәм кулланылырга тиеш булмаганнар, шуңа күрә аның шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән билгеләнгән бирелү мөмкинлеге критерийларына җавап бирми һәм шуның нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга кабул ителә алмый.

Торак урыннарны карап тоту өчен түләүне хисаплаганда кулланыла торган тарифлар күләменең һәм аларны куллану нигезләренең законлы һәм дәлилле, шулай ук карала торган күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында кабул ителгән карарның нигезле булу-булмавын тикшерү Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарының 1 һәм 2 пунктлары белән, шул карарга 2 нче кушымта белән тулысынча, шулай ук аның аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.М. Равилов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә анда куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Р.М. Равиловка һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 2-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**